КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 29 декабрь г.Казань № 1185

«Татарстан Республикасы инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының җыелма планы» мәгълүмат ресурсы турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы инженерлык инфраструктурасының җир асты һәм җир өсте объектлары турында белешмәләр булдыру һәм аларны актуаль хәлдә тоту максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының җыелма планы» мәгълүмат ресурсын булдырырга.

2. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының җыелма планы» мәгълүмат ресурсы турындагы нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге карарга таянып эш итүне, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә (Казан шәһәре муниципаль берәмлегеннән тыш) 2026 елның 30 апреленә кадәр, Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә 2030 елның 31 декабренә кадәр җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәтнамә) бирү буенча һәм проект документациясен, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топография планын килештерү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын әлеге карарга туры китерүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 29 декабрь, 1185 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы инженерлык коммуникацияләренең
һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының җыелма планы»
мәгълүмат ресурсы турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасы инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының җыелма планы» (алга таба – Җыелма план) мәгълүмат ресурсын булдыру максатын һәм алып бару тәртибен, Җыелма планга кертелә торган белешмәләр, документлар, материаллар (алга таба – белешмәләр) составын, Җыелма планны алып барганда гамәлгә ашырыла торган хезмәттәшлектә катнашучылар составын, аларның үзара хезмәттәшлек тәртибен, шулай ук Җыелма планнан белешмәләр бирү тәртибен билгели.

2. Җыелма планны булдыру максатлары – Татарстан Республикасының җир асты һәм җир өсте инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары турында белешмәләр булдыру һәм аларны актуаль хәлдә тоту, шулай ук кызыксынучы затларга Җыелма планыннан белешмәләр бирү.

2. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган терминнар һәм төшенчәләр:

функциональ заказчы – Җыелма планны булдыру, алып бару һәм үстерү барышларын оештыру һәм методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;

оператор – Җыелма планны алып баруны һәм Җыелма пландагы белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасының Пространствоны планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе;

инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары – әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында каралган Татарстан Республикасының гамәлдәге (файдаланудагы һәм файдаланудан чыгарылган, әмма сүтелмәгән) инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары;

Җыелма план – электрон рәвештә булдырыла, инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының төрләре һәм пространствода урнашу урыны турында белешмәләр бирелә торган мәгълүмат ресурсы;

Җыелма планны алып бару – Җыелма планны булдыру, Җыелма пландагы белешмәләрне актуальләштерү һәм верификацияләү, Җыелма планнан белешмәләр бирү;

үзара хезмәттәшлектә катнашучылар – әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында исемлеге каралган, Җыелма планны алып барганда үзара хезмәттәшлек итә торган затлар;

булган мәгълүматлар – үзара хезмәттәшлектә катнашучылар тарафыннан тапшырылган һәм Җыелма планда бирелгән белешмәләр, документлар, материаллар;

вектор рәвешендәге геодезия үлчәве – Җыелма планны алып бару өчен файдаланыла торган гамәлдәге инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына карата функциональ заказчы тарафыннан куелган таләпләр нигезендә, эшләрнең чикләрен күрсәтеп, вектор моделе рәвешендә әзерләнгән топография-геодезия эшләре, һәм (яки) инженерлык-геодезия эзләнүләре, һәм (яки) башкарма төшерүләр үткәрү нәтиҗәсе;

эшләр чикләре – вектор рәвешендә ясалган геодезия үлчәвенең инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары турында төгәл һәм чын белешмәләр бирелгән ябык контуры;

верификация – үзара хезмәттәшлектә катнашучыларны җәлеп итеп, шул исәптән Җыелма планны булдыру һәм актуальләштерү һәм Җыелма планнан булган белешмәләрне бирү барышында оператор тарафыннан башкарыла торган, төрле чыганаклардан яки төрле вакытта алынган белешмәләр арасында каршылыкларны (туры килмәүләрне) бетерүгә юнәлдерелгән процедура;

Җыелма планны алып бару өчен файдаланыла торган гамәлдәге инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына карата таләпләр – вектор моделе класслары тасвирламасы, инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары атрибутлары исемлеге һәм аларны тутыру кагыйдәләре, функциональ заказчы тарафыннан расланган белешмәлекләр;

вәкаләтле затлар – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территориаль планлаштыру документларын, җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрен, территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар;

гариза бирүчеләр – геодезия эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган яки инженерлык эзләнүләре һәм (яки) архитектура-төзелеш проектлау өлкәсендә үзүзен җайга салучы оешмалар әгъзалары булган индивидуаль эшмәкәрләр һәм юридик затлар, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затларның карарлары нигезендә түбәндәге документларның берсен – территориаль планлаштыру документларын, җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрен, территорияне планлаштыру документларын эшләүне тәэмин итүче затлар;

Система – «Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы;

инженерлык коммуникацияләрен һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын инвентаризацияләү – гамәлдәге инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының координатларын һәм тасвирнамәләрен билгеләүгә юнәлдерелгән геодезик һәм аналитик эшләр комплексы;

проект һәм башкарма документациясен векторизацияләү – инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының урнашу урыны турында белешмәләр бирелгән график материалларны (сызымнарны, схемаларны, планнарны) электрон төргә күчерү һәм вектор моделен булдыру эше.

4. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган, әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелмәгән башка терминнар һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган мәгънәләрдә кулланыла.

5. Җыелма план киңлек мәгълүматларының дәүләт фондына керми.

6. Җыелма планны алып бару дәүләт серен саклау турындагы законнар таләпләрен үтәп гамәлгә ашырыла.

7. Вектор рәвешендәге геодезия үлчәүләренә төгәллек «Төзелеш өчен инженерлык эзләнүләре. Төп нигезләмәләр. 11-02-96 нчы санитар нормалар һәм кагыйдәләрнең актуальләштерелгән редакциясе» дигән 47.13330.2016 нчы санитар кагыйдәләрнең кагыйдәләр җыелмасында билгеләнгән 1 : 500 масштабтагы инженерлык-топография планы төгәллегенә карата таләпләрдә билгеләнә.

8. Булган белешмәләрнең эчтәлеге һәм дөреслеге өчен, шулай ук булган белешмәләрне куллану нәтиҗәләре өчен Җыелма планга кертү өчен булган белешмәләрне биргән зат җавап бирә.

9. Җыелма планга белешмәләрне дөрес кертү өчен оператор җавап бирә.

## II. Җыелма планга кертелә торган белешмәләр составы

10. Җыелма планга түбәндәге инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары турында белешмәләр кертелергә тиеш:

а) суүткәргеч челтәре, шул исәптән су белән тәэмин итү челтәрләре һәм объектлары;

б) канализация челтәре, шул исәптән су чыгару челтәрләре һәм объектлары;

в) җылылык челтәре, шул исәптән җылылык белән тәэмин итү челтәрләре һәм объектлары;

г) газ белән тәэмин итү системасы, шул исәптән газ белән тәэмин итү челтәрләре (газүткәргечләр) һәм газ белән тәэмин итү объектлары;

д) электр челтәре хуҗалыгы объектлары, шул исәптән электр белән тәэмин итү челтәрләре һәм объектлары;

е) элемтәнең линия-кабель корылмалары, шул исәптән элемтә челтәрләре һәм корылмалары;

ж) махсус торба үткәргечләр (нефтьүткәргечләр, продукт үткәргечләр, ләмүткәргечләр, көлүткәргечләр, дулкынйөрткечләр, шлак һәм шлам үткәргечләр һәм башкалар);

з) җир асты коммуникацияләренең карый торган коелары (люклары).

## III. Үзара хезмәттәшлектә катнашучыларның функцияләре

11. Үзара хезмәттәшлектә катнашучылар:

функциональ заказчы;

оператор;

Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы ресурс белән тәэмин итүче оешмалар (алга таба – ресурс белән тәэмин итүче оешмалар), инженерлык коммуникацияләрен һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын балансta тотучылар (алга таба – балансta тотучылар);

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары).

12. Функциональ заказчы Җыелма планны төзү, алып бару һәм үстерү процессларын оештыру һәм методик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шул исәптән:

Җыелма планны алып баруны һәм үстерүне финанс белән тәэмин итүне оештыра;

Җыелма планның функциональ мөмкинлекләрен үстерү өчен функциональ таләпләрне һәм техник биремне формалаштыра;

Җыелма планны алып бару һәм үстерү өчен оештыру, норматив һәм методик яктан ярдәм күрсәтне тәэмин итә.

13. Оператор түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Җыелма планны алып бару;

булган белешмәләрне эшкәртү;

гариза бирүчеләргә булган мәгълүматларны бирү;

инженерлык коммуникацияләрен һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын инвентаризацияләү;

оператор функцияләрен башкару өчен, шул исәптән Җыелма планны алып баруны һәм үстерүне тәэмин итү өчен кирәкле товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны үткәрү.

14. Ресурс белән тәэмин итүче оешмалар, балансста тотучылар һәм җирле үзидарә органнары түбәндәгеләрне тәэмин итә:

операторга әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында каралган, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, балансста тотучылар һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы кәгазь яки электрон форматта, шул исәптән вектор форматында (булганда) булган белешмәләрне бирү;

операторга һәм аңа җәлеп ителгән затларга Җыелма планга белешмәләре кертелергә тиешле инженерлык коммуникацияләреннән һәм инженерлык инфраструктурасы объектларыннан файдалану мөмкинлеге, шулай ук Җыелма планны алып бару, шул исәптән инженерлык коммуникацияләрен һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын инвентаризацияләү эшләрен башкарганда, вәкилләр катнашында, аларның җирлектә урнашу урынын төгәлләштерү;

Җыелма планны алып бару, шул исәптән верификация эшләре кысаларында оператор һәм аңа җәлеп иткән затлар тарафыннан җибәрелә торган белешмәләрне әлеге белешмәләр алынган датадан алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча килештерү.

15. Җирле үзидарә органнары җир эшләрен башкару ордерын (рөхсәтнамәсен) төгәлләүне раслау буенча, шулай ук проект документациясен, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топографик планны килештерү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү кысаларында алынган вектор рәвешендәге геодезия үлчәүләрен операторга әлеге Нигезләмәнең V бүлегендә каралган Җыелма планны актуальләштерү тәртибе нигезендә бирүне тәэмин итә.

## IV. Җыелма планны формалаштыру тәртибе

16. Җыелма планны формалаштыру – инженерлык коммуникацияләрен һәм инженерлык инфраструктурасы объектларын инвентаризацияләүне үткәрү нәтиҗәләрен, вектор рәвешендәге геодезия үлчәве материалларын, вектор рәвешендәге генераль планнарда булган белешмәләрне һәм күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен билгеләнгән җирле координатлар системасында (ҖКС-16) инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары үзгәрүгә һәм барлыкка килүгә йогынты ясый торган башка эшләрнең белешмәләрен җыю һәм аларны Җыелма планга кертү барышы.

17. Җыелма планны булдыру эшләре оператор яки ул җәлеп иткән затлар тарафыннан дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән контракт буенча гамәлгә ашырыла.

18. Җыелма планны булдыру түбәндәге эшләрдән гыйбарәт:

ресурслар белән тәэмин итүче оешмалардан, балансtotучылардан һәм җирле үзидарә органнарыннан Җыелма планны алып бару өчен файдаланыла торган гамәлдәге инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматына карата таләпләр нигезендә вектор рәвешендәге инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары турында белешмәләр алу һәм аларны структуралаштыру;

оператор тарафыннан расланган территориаль планлаштыру документларын һәм территорияне планлаштыру документларын, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестры белешмәләрен анализлау нәтиҗәләре буенча вектор рәвешендәге инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары турында белешмәләр җыю;

инженерлык коммуникацияләрен һәм инженерлык инфраструктура объектларын, шул исәптән подряд оешмаларын җәлеп итү юлы белән инвентаризацияләү;

объектлар төзегәндә эшләнгән, инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының урнашу урыны турында белешмәләр бирелгән проект һәм башкарма документациясен, шул исәптән подряд оешмаларын җәлеп итү юлы белән векторизацияләү;

вектор рәвешендәге геодезия үлчәве материалларын җыю һәм структуралаштыру;

оператор тарафыннан алынган башка материалларны җыю һәм структуралаштыру.

19. Җыелма планга кертү алдыннан белешмәләргә верификация процедурасы уздырыла. Верификация уздырганда оператор инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының урнашу урынын һәм тасвирнамәләрен килештерү өчен хезмәттәшлектә катнашучылар адресына рәсми сораулар җибәрә.

## V. Җыелма планны актуальләштерү тәртибе

20. Җыелма планны актуальләштерү эш чикләре буенча оператор тарафыннан җирле үзидарә органнарыннан яисә башка затлардан алынган вектор рәвешендәге геодезия үлчәве нигезендә башкарыла.

21. Җир эшләрен башкаруга ордерны (рөхсәтнамәне) төгәлләүне раслаганда җирле үзидарә органнары әлеге муниципаль хезмәт күрсәтелүчедән әлеге Нигезләмәнең VII бүлегендә каралган тәртиптә килештерелгән, эшләр чикләрендә ордер (рөхсәтнамә) буенча объектлар һәм башка инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары күрсәтелгән вектор рәвешендәге геодезия үлчәвен соратып ала.

22. Проект документациясен, эшләр башкару проектын һәм инженерлык-топография планын килештерү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә җирле үзидарә органнары әлеге муниципаль хезмәт күрсәтелүчедән әлеге Нигезләмәнең VII бүлегендә каралган тәртиптә килештерелгән проект документациясен эшләү чикләрендә вектор рәвешендә геодезия үлчәүләрен, шулай ук төшерелгән үлчәүләрдә бирелгән инженерлык коммуникацияләренең һәм инженерлык инфраструктурасы объектларының дөреслеген һәм тулылыгын раслый торган документларны, материалларны соратып ала.

23. Җирле үзидарә органнары вектор рәвешендәге геодезия үлчәве җирле үзидарә органына кергән көннән алып бер эш көне эчендә Система ярдәмендә әлеге Нигезләмәнең 21 һәм 22 пунктларында күрсәтелгән муниципаль хезмәтләр күрсәтү кысаларында вектор рәвешендәге геодезия үлчәвен операторга җибәрә.

24. Җирле үзидарә органнары әлеге Нигезләмәнең 21 һәм 22 пунктларында күрсәтелгән муниципаль хезмәтләр күрсәтелүчеләргә Система аша операторның Җыелма планны актуальләштерү процедурасы тәмамлану турында раславын алганнан соң аларны күрсәтү нәтиҗәләрен җибәрә. Әгәр дә әлеге Нигезләмәнең 27 пунктында каралган нигезләр булса, оператор җирле үзидарә органына, сәбәпләрен күрсәтеп, Җыелма планны актуальләштерү мөмкин түгеллеге турында хәбәр җибәрә, ә җирле үзидарә органы әлеге Нигезләмәнең 21 һәм 22 пунктларында күрсәтелгән муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

25. Җыелма планны актуальләштерү процедурасы әлеге Нигезләмәнең 23 пункты нигезендә вектор рәвешендә алынган геодезия үлчәвен, аны эшләр чикләре буенча Җыелма планга кертүне, әлеге Нигезләмәнең 24 пунктында күрсәтелгән Җыелма планны актуальләштерү процедурасы тәмамлануының оператор тарафыннан раслануын үз эченә ала.

26. Җыелма планны актуальләштерү яки җирле үзидарә органына Җыелма планны актуальләштерү мөмкин түгеллеге турында хәбәр җибәрү срогы оператор тарафыннан Система аша әлеге Нигезләмәнең 21 һәм 22 пунктларында күрсәтелгән, муниципаль хезмәтләр күрсәтү кысаларында алынган, вектор рәвешендә төшерелгән геодезия үлчәве кергән көннән алып иң күбе биш эш көнен тәшкил итә.

27. Җирле үзидарә органына Җыелма планны актуальләштерү мөмкин түгеллеге турында хәбәр җибәрү өчен нигезләр:

а) җирле үзидарә органы тарафыннан җибәрелгән вектор рәвешендәге геодезия үлчәве материаллары эшләр чикләренә туры килмәү;

б) вектор рәвешендәге геодезия үлчәвендә булган инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары турында белешмәләрдә каршылыклар булу;

в) җирле үзидарә органы тарафыннан җибәрелгән вектор рәвешендәге геодезия үлчәве материалларында инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары тулы күләмдә чагылдырылмау;

г) җибәрелгән материаллар Җыелма планны алып бару өчен кулланыла торган гамәлдәге инженерлык коммуникацияләре һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары форматы таләпләренә туры килмәү.

## VI. Җыелма планнан булган белешмәләрне бирү

28. Җыелма планнан булган белешмәләрне бирү гариза бирүченең Җыелма планнан белешмәләр бирү турында мөрәҗәгате (алга таба – Мөрәҗәгать) нигезендә башкарыла.

29. Мөрәҗәгать оператор адресына электрон почта яки электрон сервислар, шул исәптән Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша җибәрелә.

30. Мөрәҗәгатьне үтәү нәтиҗәсе:

а) Җыелма планнан булган белешмәләрне бирү;

б) Әлеге Нигезләмәнең 34 пунктында каралган очракларда, Җыелма планнан булган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

31. Мөрәҗәгатьне үтәү срогы операторга Мөрәҗәгать кергән көннән алып биш эш көне тәшкил итә.

32. Мөрәҗәгатьне үтәү өчен гариза бирүче операторга ирекле формада гариза тапшыра, анда кирәкле белешмәләрне алу өчен башкарылырга тиешле эшләр күрсәтелә, түбәндәге документлар теркәлә:

а) гариза бирүчегә булган белешмәләр таләп ителә торган вектор рәвешендәге чикләр (алга таба – рәсми сорау контуры);

б) геодезия эшчәнлеген башкару лицензиясенең күчермәсе, инженерлык эзләнүләре һәм (яки) архитектура-төзелеш проектын ясау өлкәсендә үз-үзен җайга салучы оешмалар реестрыннан өземтә яисә гариза бирүче тарафыннан территориаль планлаштыру документлары, җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документациясе эшләү тәэмин ителгән очракта – гариза бирүче тарафыннан әлеге документларның берсе эшләнә башлау турында вәкаләтле затлар карары.

33. Гаризага һәм аңа теркәлә торган документларга гариза бирүченең гади электрон цифрлы имзасы куела.

Гаризага теркәлә торган электрон документлар (документларның электрон сурәтләре)(эшләр контурыннан тыш) иң күбе 50 Мбайттан артмаган зурлыкта .pdf, .jpg, .jpeg, .png, .tiff, .sig форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Тапшырыла торган электрон документларның (документларның электрон сурәтләре) сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

34. Җыелма планнан булган белешмәләрне бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

а) рәсми сорау контурының мәйданы 100 гектардан артып китә (Мөрәҗәгать территориаль планлаштыру документларын, җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрен, территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итә торган гариза бирүче тарафыннан вәкаләтле затларның әлеге документларның берсен эшли башлау турында карары нигезендә җибәрелгән очрактан тыш);

б) бер календарь ай эчендә бер гариза бирүче тарафыннан соралган рәсми сораулар контурларының гомуми мәйданы 1 000 гектардан артып китә (Мөрәҗәгать территориаль планлаштыру документларын,
җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләрен, территорияне планлаштыру документларын әзерләүне тәэмин итә торган гариза бирүче тарафыннан вәкаләтле затларның әлеге документларның берсен эшли башлау турында карары нигезендә җибәрелгән очрактан тыш);

в) гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган текстны бозып төзәтүләр һәм төзәтмәләр булу;

г) гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларда Мөрәҗәгатьне үтәү өчен гариза бирүче документларындагы белешмәләрне тулысынча файдаланырга мөмкинлек бирми торган зарарланган урыннар булу;

д) тапшырылган документлар Мөрәҗәгать алынган вакытта үз көчен югалткан булу;

е) гариза һәм Мөрәҗәгатьне үтәү өчен теркәлә торган кирәкле документлар әлеге Нигезләмәнең 34 пунктында каралган таләпләрне бозып бирелү;

ж) гаризада һәм теркәлә торган документларда дөрес булмаган белешмәләр булу;

з) әлеге Нигезләмәнең 32 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге тулысынча бирелмәү;

и) электрон рәвештә бирелгән документларда «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имза гамәлдә булу шартлары үтәлмәү;

к) Җыелма планның сорала торган өлешенә карата аны таратуга режимлы чикләүләр билгеләнү;

л) Җыелма планның сорала торган өлеше дәүләт серен тәшкил итү.

35. Гариза бирүче алынган белешмәләрне бары тик Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән эшләр кысаларында гына кулланырга, шулай ук аларны өченче затларга тапшырмаска бурычлы.

## VII. Вектор рәвешендәге геодезия үлчәвен килештерү тәртибе

36. Вектор рәвешендәге геодезия үлчәве Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр» гамәли платформасының бердәм килештерүләр кабинеты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2024 ел, 15 июль, 558 нче карары белән расланган «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр» гамәли платформасының бердәм килештерүләр кабинеты турындагы нигезләмәнең 1.2 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр» гамәли платформасының бердәм килештерүләр кабинетында килештерелергә тиеш.

37. Әлеге Нигезләмәнең 36 пункты нигезендә вектор рәвешендәге геодезия үлчәвен килештерүнең техник мөмкинлеге булмаган очракта, килештерү ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, балансста тотучылар һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан эшләр чикләрендә вектор рәвешендәге геодезия үлчәвенең дөреслеген һәм тулылыгын раслый торган документ бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.